Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) Территориаль планлаштыру турында нигезләмә
2) торак пунктлар чикләре урнашу урыны тасвирламасы

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

Ачык тыңлаулар 01.09.2025 тән 26.09.2025 елга кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
-гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати
-материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозициясен ачу;
- проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Керкәле һәм Тукмак авылларында үткәрелә.

2025 елның 01 сентябреннән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге генераль планы проектының ачык тыңлауларда каралырга тиешле экспозициясен авыл җирлеге администрациясе бинасында: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Керкәле авылы, Совет ур., 93 й. адресы буенча ачарга.
Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 01.09.2025дан 26.09.2025га кадәр

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга генераль план проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, ТР, Лениногорск муниципаль районы, Керкәле авылы,Совет ур., 93 йорт адресы буенча кертергә яисә Kark.Len@tatar.ru, яисә 2025 елның 17 сентябрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып кую юлы белән.

Язма рәвештә бирелгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә түбәндәге документларның күчермәләре кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен-яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган шәхесне таныклаучы документның күчермәсе һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык; юридик затлар өчен- «Шәхси мәгълүматлар турында» ЕГРЮЛдан өземтә.

Экспозиция эше барышында «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультацияләр бирергә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

2025 елның 17 сентябрендә 17.30 сәг., адресы: Керкәле ав., Совет ур., 93 й.;

2025 елның 17 сентябрендә 18.30 сәг., адресы: Тукмак авылы, Чкалов ур., 48 йорт.

2025 елның 01 сентябренә кадәр Генераль план проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет ур., 93 йорт; Тукмак авылы, Чкалов ур., 48 йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районының
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И. Бигманов